**Карар № 7**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге Советы

Таш-Чишмә авылы "19" декабрь 2025 ел

**Өҗем авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 107 номерлы карары белән расланган "Өҗем авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2025 елның 21 апрелендәге 84-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен туктатып тору, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен гамәлдән чыгару һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын 2025 елда үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2025 елның 12 декабрендәге 020802-2025/Прп368-25 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Өҗем авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге № 107 карары белән расланган (№ 121 10.02.2020 ел, № 128 28.05.2020 , № 7 30.10.2020 , №33 06.12.2021 , №43 16.05.2022, №47 17.08.2022 , №77 27.10.2023 , №90 05.06.2024, №111 21.04.2025 ел үзгәрешләре белән) "Өҗем авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1.1. 21 статьяның 3 пунктының икенче, өченче һәм алтынчы абзацларында** «муниципаль-шәхси партнерлык килешүләре ягыннан» дигән сүзләрдән соң «(гавами партнерның, капиталь грантның түләү күләмендә)» сүзләрен өстәргә;

**1.2. 21 статьяның 3 пунктының дүртенче абзацында** «Күрсәтелгән чикләү кагылмый» сүзләрен «Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән чикләүләр кагылмый» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.